**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 декабрь № 925

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы структурасына үзгәреш кертү турында» 2016 ел, 6 декабрь, ПУ-1075 нче Указын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы мәсьәләләре» 2005 ел, 6 июль, 313 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 26 сентябрь, 464 нче; 2005 ел, 1 ноябрь, 517 нче; 2005 ел, 29 декабрь, 661 нче; 2006 ел, 1 март, 87 нче; 2006 ел, 21 апрель, 198 нче; 2006 ел, 9 июнь, 293 нче; 2007 ел, 18 май, 196 нчы; 2007 ел, 25 май, 199 нчы; 2008 ел, 28 гыйнвар, 41 нче; 2008 ел, 15 июль, 509 нчы, 2009 ел, 5 июнь, 360 нчы; 2009 ел, 17 август, 551 нче; 2010 ел, 8 июнь, 440 нчы; 2010 ел, 14 октябрь, 808 нче; 2010 ел, 2 декабрь, 976 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 7 октябрь, 838 нче; 2011 ел, 15 ноябрь, 935 нче; 2012 ел, 18 гыйнвар, 25 нче; 2012 ел, 22 август, 726 нчы; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2013 ел, 18 февраль, 110 нчы; 2013 ел, 7 март, 152 нче; 2013 ел, 27 апрель, 286 нчы; 2013 ел, 10 август, 558 нче; 2014 ел, 11 март, 153 нче; 2014 ел, 21 апрель, 261 нче; 2015 ел, 1 июнь, 397 нче; 2016 ел, 10 октябрь, 733 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктның икенче абзацында «163» саннарын – «164» саннарына, «820,198» саннарын «827,759» саннарына алмаштырырга;

3 нче пунктта «министрның алты урынбасары, шул исәптән ике беренче урынбасары» сүзләрен «министрның җиде урынбасары, шул исәптән бер беренче урынбасары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасының Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына законнар нигезендә әлеге карарның 1 нче пунктын гамәлгә ашыруны тәэмин иткән оештыру карарлары кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\925.doc